РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ
ТАКТАЛАЧУКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423751, село Такталачук,
ул.Г.Авзал, дом 48, Тел. 3-44-57

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАКТАЛАЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

423733,Такталачык авылы, Г.Авзал ур.,
48 нче йорт. Тел.3-44-57

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«18» январь 2021 ел** **№3**

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлегендә балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиянең 2021 елга эш планын раслау турында**

«Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 14.10.2011 № 71-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Такталачык авыл җирлеге Уставы нигезендә, балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны кисәтү һәм профилактикалау, гаиләләр белән профилактик эш алып бару максатыннан
**КАРАР БИРӘМ**:

1. Такталачык авыл җирлеге башкарма комитеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре буенча иҗтимагый комиссиянең эш планын (1 нче кушымта) расларга.
2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми pravo.tatar.ru сайтында, Такталачык авыл җирлеге http://aktanysh.tatar.ru/rus/aktanysh/poselenia сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе М.Т.Мансуров

Такталачык авыл җирлеге
Башкарма комитет
җитәкчесенең
18.01.2021 ел №3 карарына
кушымта

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең

2021 нче елга эш планы

| №<br>п/п | Мероприятие | Үтәү вакыты | җаваплы | Кем белән берлектә уткәрелә |
|---|---|---|---|---|
| | Оештыру-методик эш | | | |
| 1. | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия утырышы (Татарстан Республикасы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районындагы беркетмәләре һәм күрсәтмәләре буенча балигъ булмаган балаларга һәм аларның ата-аналарына карата материалларны карау, белем бирү учреждениеләре тәкъдимнәре һәм утенечнамәләре, гражданнарның шикаятьләре, торак шартларын тикшерү актлары һ. б.) | Кварталга 1 тапкыр | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 2. | Такталачык авыл җирлеге авылларында КБН һәм ЗП кучмә утырышларын уткәрү | Квартал саен | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 3. | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рейдлары | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4. | Балигъ булмаганнар арасында эчкечелекне кисәтү максатыннан яшүсмерләр концентрациясе урыннары (дискотекалар, урамнар) буенча рейдлар | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 5. | Сәүдә нокталары буенча рейдлар | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 6. | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы КДН һәм ЗП утырышларында чыгарылган штрафлардан качып йөрүче гражданнар буенча рейдлар | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 7. | Имин булмаган гаиләләрне ачыклау һәм аларны КДН, ЗП һәм ПДНда исәпкә кую | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 8. | Балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча яшүсмерләр һәм аларның ата-аналарын кабул итү | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 9. | Гаилә көненә, Балаларны яклау көненә, Яңа елга багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |

балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия утырышында карау өчен чыгарылган мәсәләләр

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге территориясендә балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларның һәм җинаятьләрнең торышы турында | Квартал саен | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 2. | Дәресләргә йөрмәгән балалар турында һәм мондый очракларга юл куймау буенча җирлек мәгариф | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | учреждениеләре тарафыннан күрелгән чаралар һәм балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия составы турында мәгълүмат | | | |
| 3. | Яшәү урыны буенча Балигъ булмаганнарның ялын оештыру турында | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 4. | Күп балалы һәм имин булмаган гаиләләр белән эшләү | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |
| 5. | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссия эшенә йомгак ясау | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | Комиссия составы |